

# ТЕМА: Г.САБИТОВНЫҢ “ЯРСУЛЫ ЯЗ” ХИКӘЯСЕНДӘ ТАБИГАТЬНЕ БАЛА КҮҢЕЛЕ АША ТАСВИРЛАУ

ДӘРЕСНЕҢ МАКСАТЫ:

ПРОЗА ӘСӘРЛӘРЕН АНАЛИЗЛАРГА ӨЙРӘТҮ; ӘСӘРНЕҢ ТЕЛЕН, ЯЗЫЛУ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН ТИКШЕРҮ; ФИКЕРЛӘҮ СӘЛӘТЕН ҮСТЕРҮ; ТАНЫП-БЕЛҮ ОСТАЛЫГЫН ҮСТЕРҮ; ЧЫН ДУСЛЫК, ХӨРМӘТ ХИСЛӘРЕ ТӘРБИЯЛӘҮ.



Яз
килде





Хикәя нәрсә ул?

“Ярсулы яз” ни өчен хикәя дип атала?

Хикәя – тормышта булган һәм булуы ихтимал берәр вакыйганы сурәтләгән кечкенә күләмле чәчмә әсәр.



Әдәби әсәрләрнең дә идеясе, нигезе, “тамырлары” була. Язучы иң әүвәл тема таба, образлар тудыра, вакыйгаларны үстерә башлый, сюжет кора, аларны матур тел-стиль чаралары белән бизи.



# Сүзлек эше:

- Каралама –
- Борыс –
- Гөлбәч –
- Күлдәвек –
- Бәкәл –
- Элпә -

# Сүзлек эше:

- Каралама – кәгазь бите
- Борыс – ишек, тәрәзә кырыен ясау өчен агач материал
- Гөлбәч – мич арасы
- Күлдәвек – җыелып торган кечкенә сулык
- Бәкәл – тояклы хайваннарның аякларында, тояктан өстә чокырланып торган буынтык
- Элпә – тере организмда тышча, пәрдә булып хезмәт итүче яры.

# Физкульт.минутка



- Текст өстендә эш. Яз билгеләре.





- Бирем:
- 1. Гамил кичерешләрендә яз ничек сурәтләнә?
- 2. Гөлүсәгә карата хисләре нинди?
- 3. Гөлүсәнең телдән рәсемен ясыйк.



Синдәдер ул йөрәкләрнең
иң олысы,
Синдәдер ул йөрәкләрнең
иң җылысы,
Һәркөн сиңа ничә сабый
карап тора
Алар сине әтиседәй якын
күрә.
Еласалар, син аларны
юатасың,
Боексалар, син аларны
уйнатасың,
Сөйләшәсең күңелләрен
аңлап кына,
Орышасың кайчагында
җайлап кына.
Укытучы!
Кирәк чакта җитез дә син,
тапкыр да син,
Кирәк чакта батыр да син,
сабыр да син,
Бик җаваплы, авыр синең
хезмәтең дә,
Тиешенчә күрсәң иде
хөрмәтен дә



Күбәләк –
мәхәббәт
һәм
матурлы
к
символы

# Әсәрдәге образларга сыйфатлама

| Вакыйга | Гамил | Гөлүсә | Галләм абый |
| --- | --- | --- | --- |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

# Өсәрдәге образларга сыйфатлама

| вакыйга | Гамил | Гөлүсә | Укытучы – Галләм абый |
| --- | --- | --- | --- |
| 1. Мәктәптә, математикадан контроль эш. | Тырыш, яхшы укучы, ярдәмчел | Ялкаурак, иренчәк, иркә, мәче кебек мәкерле | Төгәл, ипле, җор телле, сизгер, үткен күзле, итәгатьле, бала җанлы |
| 2. Өйгә кайту юлында. | Сизгер, шаян, матурлыкны күрә белә | | |
| 3. Өйдә. | Пөхтәлек ярата, эшчән, мәрхәмәтле | | |
| 4. Тыкрыкта. | Тиз кызып китүчән, тик усал түгел | Кыю, шаян телле, актив, әрепләшә, тик усал түгел, яхшы күрше һәм яхшы дус. Чибәр, нечкә билле, озын матур кие керфекләре, | Сугышта булган, күпме авырлык күргән, авырдан атлый, кырыслыгы да бар, хөрмәтле укытучы |
| 5. Өйдә | Сабыр, игътибарлы | | |

# Бирем җаваплары:

- **Фразеологик әйтелмәләр**: күпер башында кар яна, башына тай типмәгән, күрше хакын хакладым, читтән суктырачак, утереңне карга чукыган, һавадан тургай санап йөри, канга тоз салу, кирәкле кишер яфрагы, авыз ачып тору, көле күккә очу, уеннан – уймак, бәла аяк астында, кешегә чокыр казу.

# Бирем җаваплары:

- **Чагыштырулар:** мәче баласы ничек караса, дәфтәргә шулай карап калды Гөлүсә; җим көткән чебеш кебек; гәрәбәдәй сары нарат стеналар; койрыклары камчыдай; карлар чәйдә эрегән шикәр кебек; ак бәкәлле колын кебек һ.б.

- Эпитет - күренеш һәм предметның сыйфатын, аерым билгеләрен белдерүче сурәт. Җөмләне бизәп тора.
- Чагыштыру – бер предметны яки күренешне икенче предметка һәм күренешкә охшатып әйтүне белдерә.

# Өй эше

- 1. Яраткан укытучыгыз турында кечкенә хикәя язып килергә.

- Игътибарыгыз өчен рәхмәт
- Уңышлар телим

